ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

08.08.2016 — 23

с. Кильдеево

Килди авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүләр бирүнең административ регламентларын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. Расларга:

1.1. Күчемсез милек объекты адресын бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1нче кушымта).

1.2. Гражданга социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль милектәге торак урын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты(2 нче кушымта) .

1.3. Кадастр исәбенә кую максатында муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре чикләрен килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (3 нче кушымта).

1.4. Җир кишәрлегенә белешмә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты, йорт биләмәсенә белешмә, гаилә составы турында белешмә, яшәү урыныннан белешмә, хуҗалык кенәгәсеннән өземтә (4 нче кушымта).

1.5. Документларның күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (5 нче кушымта).

1.6. Җир кишәрлеген сайлау актын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (6 нчы кушымта).

1.7. Торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (7 нче кушымта).

1.8. Җирлекнең генераль планыннан өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (8 нче кушымта).

2. «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2013 елның 25 мартындагы 9 номерлы Килди авыл җирлеге башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Килди авыл җирлегенең «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге территориясендә күчемсез милек объектын бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 10 декабрендәге 45 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районының
Килди авыл җирлеге башлыгы

В. М. Бурдин